**Сөйләм.** Кешеләрнең әйтеп Һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.

**Җөмлә һәм сүз.** График схемалар ярдәмендә сөйләмне —җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату.

**Иҗекләр.** Сузык аваздан торган һәм сузык аваздан башланган иҗекләр *(уа, ил, ант),* кушылмадан торган һәм кушылма авазлардан башланган иҗекләр *(чабу, күл-мәк, сирт-мә, шо-мырт).* Сузык авазларга басым ясап *(у-мар-та)* яки суза төшеп *(әә-реек-мәән),* сүзләрне иҗекләргә бүлеп әйтү һәм сүздәге иҗекләр санын сузык авазларга карап билгеләү.

**Авазлар һәм хәрефләр**. Аваз турында күзаллау тудыру. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп. ягъни конкрет авазны әйткәндә авыз эчендә сулышның тоткарлануы яки тоткарланмавына *(т — а),* калын яки нечкә әйтелүенә *(а — ә),* яңгырап яки пышылдап ишетелүенә *(з - с)* карап аера белү. Авазларны әдәби дөрес әйтү.

Аерым (сузык яки тартык) авазны сүздән аерып алу сүзләргә иҗек-аваз анализы ясау (сүзләрдәге авазлар санын, аларның характерлы билгеләрен, сүздәге тәртибен күрсәтә әйтелгән һәм ишетелгән сүзләрне аларның иҗек-аваз төзелешен күрсәткән схема-модельләр белән бәйләү, ягъни конкрет сүзнең иҗек һәм авазларын сүздәге тәртиптә схемада күрә белү.

Укытучы тәкъдим иткән аваз кергән сүзләрне мөстәкый уйлап табу *(ш: таш, шар, шешә...);* сүзләрнең әзер иҗек-аваз схемаларын эзләп табу.

Калын сузык авазларны белдергән, *а, у, ы* һәм нечкә сузык авазларны белдергән *ә, ү, и* хәрефләре белән таныштыру; сузык аваз хәрефләрен, шул хәрефләрдән төзелгән сүзләрне укырга өйрәтү *(ә, әү, у, и, иа!, ау!)*

## Әлифба чоры, яки төп чор

## Укырга өйрәтү

Сузык һәм тартык авазлар һәм аларның хәрефләре белә сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләүче калы һәм нечкә сузык авазлар белән танышу. Сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтеп укылуын күзәтү *(урыла — үреләә).*

Сузык аваз хәрефләренә карап, кушылмадан торган (ике хәрефле ачык) иҗекләрне, өйрәнелгән хәрефләрдән төзелгән иҗекләрне телдән аваз анализы һәм синтезы ясалганнан соң уку.

Башта — аваз анализы ясап, алга таба анализ ясамыйк гына күңелдән әйтеп, кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан *(та, ла, тә, ти)* сүзләр төзү һәм төзелгән сүзләрне кычкырып уку.

Хәрефләрне дөрес һәм чагыштырмача тиз танып, җанлы сүздәге авазлар мәгънәсендә уку *(эре — [эрэ], тиен -[тийэн], юкә — [йүкә], юка — [йукъа]* һ. б.). Сузыктан башланган ике хәрефле *(ал, ит, үт),* сузыктан һәм кушылмалардан торган ике иҗекле *(а/ла, тә/ти, ә/ти)* сүзләрне уку; аннары артикуляцион берәмлекләр буенча кушылмалардан башланган иҗекләрдән төзелгән сүзләрне уку *(мә, мә:к т.ә:п; кө:р:т ле:к, ба:л ты:р га:н);* ахырдан сүзләрне турыдан-туры иҗекләп, кыска һәм гади сүзләрне бөтен килеш әйтеп уку. Сүзләрне, кыска гади җөмләләрне, балаларга аңлаешлы кечкенә текстларны аңлап, әдәби дөрес һәм салмак итеп, сүзләп кычкырып укырга эзлекле күнектерү.

Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә (нокта, сорау, өндәү), җөмлә эчендәге тиңдәш кисәкләргә, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп, укытучы үрнәгендә укырга өйрәнү.

У ку гигиенасы кагыйдәләре белән балаларны таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү.

## Кычкырып укырга тәкъдим ителгән балалар әдәбияты тематикасы

Туган илем, туган телем, Ватаным Татарстан, гомумкешелек, әдәп-әхлагы, гаилә тормышы, уку һәм хезмәт сөю, халкыбыз тарихында милли азатлык өчен көрәш сәхифәләре, халыклар дуслыгы, тереклек һәм үсемлекләр дөньясында кеше, ел фасыллары, маҗаралар, тылсымнар турында язучылар һәм халык иҗат иткән, хис һәм кичерешләргә бай әсәрләр (хикәя, әкият, җыр, шигырь, мәзәк, табышмак, мәкаль).

## Балалар китабы белән эшләү

Китап уку даирәсен формалаштыру (һәр дәрескә — бер китап). Балалар өчен басылган китаплар белән кызыксындыру, китапларны эчтәлегенә карап аера белергә өйрәтү, киитап, әсәр исемнәрен дөрес әйтү, китапны язган кешенең (авторның) исемен укып күрсәтү. Дәрестә, дәрестән тыш укылган китап, әсәр буенча гади генә уеннар оештыру. Сөйләгәндә, әсәрдән алынган әдәби сөйләм үрнәкләреннән файдалану (сүзләр, сүзтезмәләр, әйтемнәр, мәкальләр, җор җөмләләр һ. б.).

Уку гигиенасы һәм китапны саклап тоту кагыйдәләрен утәү.

## Әйтмә сөйләмне үстерү

Сөйләмнең аваз культурасы. Балаларда үз сөйләменең, шулай ук башка кешеләр сөйләменең авазларына игътибарны көчәйтү; ишетү сизгерлеген һәм хәтерен, сөйләм органнары хәрәкәтен үстерү, шомарту. Сөйләмнең гомуми күнекмәләрен камилләштерү, сөйләмнең салмак темпы һәм ритмына, сөйләм сулышына һәм агышына, уртача тавышка (көчәнмичә кычкырып сөйләүгә) һәм дөрес интонациягә (тавышны күтәрә, түбәнәйтә белергә) өйрәтү.

Сүзләрне (аеруча иҗек-аваз төзелеше катлаулы булганнарын) орфоэпия нормаларына туры китереп, басымнарны саклап әйтүне эзлекле камилләштерә бару. Туган телдәге парлы авазларны әдәби дөрес әйтү, аеруча балалар еш бутый, бозып әйтә торган *з — с, ч — с, н — ң, х — һ, ш — ж, җ* — й, *п — б, w — в* Һ. б. авазларны ишетеп аера, дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү (сүзләрдә, җөмләләрдә, тизәйткеч, тел чәбәләндергечләрдә анык итеп әйтү).

Кайбер сөйләшләрдә әдәби нормадан читкә чыккан кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү *(туНган, боДау, баргаЛЛар, әйтсәнДӘГЕН, Йомга, СҮли* һ. б.).

Сүз өстендә эшләү. Балаларның сүзлеген (сүзлек хәзинәсен) ачыклау, аныклау, баету һәм активлаштыру. Предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдергән, хәрәкәт вакытын һәм урынын күрсәткән (кичә, бүген, иртә, иртә иртәгә, ары, бире, монда, алда, читтә, өстә, югары, эчтә, тышт түбән, аста һ. б.) сүзләрне дөрес (урынлы) куллану һәм аларның мәгънәләрен аңлату. Мөһим билгеләре буенча предметларны берләштерү һәм аеру, төркемне һәм төрне атаган сүзләрне дөрес куллану *(хайван, кош, җәнлек, сыер, болан, тавык, көртлек* һ. б.). Уйны төгәл белдерү өчен кирәк булган сүзләрне таба һәм аларны дөрес грамматик бәйләнешкә кертә белү *(кичә кич, иртәгә иртән, чибәр йөз, зифа буй, матур гөл, тактага яза, тактада чишә, сузык аваздан башлана, тортык авазга бетә, күргәзмә оештыра, күрсәтмә әсбап ясый* һ. б).. Сүзләрнең мәгънә төсмерләренә сизгерлек сыйфатын үстерү күп мәгънәле, мәгънәдәш, капма-каршы мәгънәле сүзләрне иң гади мисалларда тану, аеру. Әдәби әсәрләрдәге күчерелмә мәгънәдә (образлы итеп) кулланылган сүзләрне, әйтелмәләрне балаларның үз сөйләмендә кулланырга өйрәтү.

Сүзләрне грамматик дөрес формада куллану, сөйләмне әдәби дөрес булмаган сүзләрдән арындыру.

**Җөмлә төзү һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү.**

Балаларның мәктәпкәчә яшьтә ирешкән сөйләү осталыгын камилләштерү. Укытучы соравына биреләчәк җавапны яхшылап уйлап җиткерү, анык, төзек һәм кыска гына төгәл итеп әйтү. Җавапта төрле тип җөмләләр куллану.

Текст кисәкләрен төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча, таныш әкият яки хикәя эчтәлеген укытучы сораулары буенча сөйләү.

Рәсем яки рәсемнәр сериясе буенча гомуми бер темага берләштерелгән җөмләләр яки сюжет логикасы сакланган кечкенә хикәяләр төзеп сөйләү.

Укылган җөмләләргә яки текстларга карата куелган сорауларга телдән җавап бирү.

Әдәби әсәрдәге хәлләргә бәйле сүзләрне кулланып, төрле күренешләрне укытучы ярдәмендә телдән сурәтләү. Сюжетны тулыландыру, кечкенә хикәя башына, аеруча ахырына, мөстәкыйль рәвештә төрле күренеш һәм хәлләр уйлап чыгарып өстәү.

Укыган хикәядәге вакыйгаларга охшашлык буенча яки укытучы тәкъдим иткән сюжет буенча балаларның үз тормышында булган хәлләр турында телдән кечкенә хикәяләр төзеп сөйләүләрен оештыру.

Табышмакларны җентекләп аңлату; шигырь, җыр, такмак, такмаза, сынамыш, тизәйткеч һәм мәзәкләрне ятлау, эчтәлек таләп иткән дәрәҗәдә аларны төрле интонациядә сөйләү.

Үз хикәяләрен телдән иншалаганда һәм укыган текст эчтәлеген сөйләгәндә, балалар сөйләменең грамматик дөреслеген, төгәллеген, тулылыгын, хисләргә, кичерешләргә бай, эзлекле, эчтәлекле һәм нәфис булуын үстерү.

Башка укучыларның җавапларына һәм сөйләмнәренә игътибарлы һәм теләктәш мөнәсәбәттә булу сыйфатын һәр укучыда тәрбияләү.

**Әлифбадан соңгы чор**

**Шигырь һәм проза.** Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми күзаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

**Халык авыз иҗаты һәм әдәбият.** Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).

**Әсәрнең эмоциональ тоны.** Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерны чагылдыра белү. Тавыш төсмерләре: интонация, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.

**Әдәби сәнгатьлелек чаралары.** Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: «рифма», «ритм» төшенчәсе бирү.

**Әдәби жанрлар.** Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру.

**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү, әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.

**Шигырь.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьләрнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүләренә инандыру. Рифма белән танышу: аны таба һәм куллана белергә күнектерү.

**Библиографик культура.** Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: «Эчтәлек» битеннән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп табу.

**Уку күнекмәләре.** Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү.

## Туган телдә әдәби уку фәненең курс эчтәлеге
## 2 сыйныф

**Халык авыз иҗаты**

**Хайваннар турында әкиятләр.** Әкиятләр турында гомуми кузаллау. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.

**Тылсымлы әкиятләр.** Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар, (эченнән гаскәр чыга торган таяк,төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше  күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ. б., герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар ( җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, убырлы карчык, һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелеше).

Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).

**Автор әсәрләре**

Шигъри формада язылган тылсымлы әкиятләр (Г. Тукай “Кәҗә белән сарык әкияте”), аның халык әкиятләре белән охшашлыгы, сюжет һәм композиция үзенчәлеге. Капма-каршы  ике төрле дөнья бирелеше ( җирдәге һәм тылсымлы, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әйберләр, тылсымлы төсләр). Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Халык авыз иҗаты белән охшашлык (кабатланулар, вакыйгалар бергәлеге һ.б.)

**Хикәя жанры.** ( А. Әхмәт, Г. Ибраһимов, И. Туктар, Л.Лерон,Ә Моталлапов, Э. Шәрифуллина).Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең  төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.

**Шигърият**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.  Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык .Чагыштыру, контраст,, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын  үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче.. тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү)

**Библиографик культура формалаштыру.**

"Эчтәлек " белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү.Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау.

**Туган телдә әдәби уку фәненең курс эчтәлеге**
**3 сыйныф**

**Хайваннар турында әкиятләр.** Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөрүче хайваннар турындагы әкиятләр турында гомуми кузаллау булдыру. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында кузаллау булдырыла.

**Мәсәлләр жанры.** Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (тарихи вакыйга) һәм мораль (нәтиҗә, тәрбияви аңлатулар) торуын аңлату. Мәсәлнең хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы. Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтендөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж. Лафонтен, И. Крылов, татар мәсәлчеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Т. Яхин, Г. Шамуков, Ә. Исхак, Ф. Яхин һәм башкалар турында өйрәнү.

**Мәкаль жанры.** Мәкальләр – ул борынгылар сүзе, аталар сүзе, картлар сүзе, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше, хәтердә сакланырга тиешле хәзинә, халыкның күмәк фикере, тормыш кагыйдәсе, сүзгә дәлил, тормышта киңәш. Мәкаль сүзе гарәп теленнән алынган, "урынлы сүз якитиешле урында әйтелгән сүз" дигән мәгънәне аңлатуын төшендерү. Төрле халыклар мәкальләре. Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану.

**Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыру.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (*тавышны күтәрү, түбәнәйтү*).

**Вакыт тасмасы**. Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү(*бик борынгы, борынгы, әкияти вакыйгалар*)

**Библиографик культура формалаштыру.**

"Эчтәлек " белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү

**Туган телдә әдәби уку фәненең курс эчтәлеге**
**4 сыйныф**

**Халык авыз иҗаты**

**Мифлар турында гомуми кузаллау булдыру.** Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.** Дөнья турында борынгы кузаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы, тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә, максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы). Халыклар әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.** Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлятьар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгзн вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре.** Автор әкиятләренеңхалык әкиятләре белән охшашлыгы. (жанр һәм сюжет). Халык әкиятләрендәге тылсым белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя.** Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыруны дәвам итү**.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой характерының катлаулылыгы, вакыт белән бәйләнеше. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында**

Шагыйрь, язучы, рәссамнарның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылышы;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. Әсәр авторлары турында мәгълүмат туплау.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.** Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

**Тематическое планирование.**
**Тематик планлаштыру**
**1-класс**

| **т/с** | **Название раздела.**<br>**Бүлек исемнәре** | **Кол-во часов**<br>**Сәгать саны** |
|---|---|---|
| 1. | Добукварный период.Әзерлек чоры. | 3 |
| 2. | Букварный период.Әлифба чоры. | 20 |
| 3. | Послебукварный период.Әлифбадан соңгы чор. | 10 |
| 4 | Мой родной язык-татарский.Туган телем - татар теле. | 1 |
| 5 | Семья. Гаилә. | 1 |
| 6 | Этика-эстетика. Әдәп – әхлак. | 1 |
| 7 | Где труд, там и счастье. Иң мөкатдәс нәрсә – эш. | 1 |
| 8 | Растительный и животный мир.Үсемлекләр һәм җәнлекләр дөньясы. | 1 |
| 9 | Весна идет. Яз килә, яз көлә. | 1 |
| 10 | Зима наступила. Кыш килде. | 1 |
| 11 | Татарское устное народное творчество.Татар  халык авыз иҗаты | 1 |
| 12 | Известные татарские писатели. Күренекле татар язучылары. | 1 |
| 13 | Лето. Ямьле җәй җитә. | 1 |
| | Всего<br>Барлыгы | 33 |

**Тематическое планирование / Тематик планлаштыру**
**2-класс**

| т/с | Названия глав/ Бүлек исемнәре | Кол-во часов<br>Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | В гостях у знающего Ежа/Белдекле керпедә кунакта | 20 |
| 2 | В гостях у Незнайки/Белмәмештә кунакта | 4 |
| 3 | У образованной Совы/ Укымышлы Ябалак янында | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | В берлоге у Медведя/Аю өнендә | 2 |
| 5 | Точка зрения/Күрү ноктасы | 22 |
| 6 | Газеты и журналы для детей/Балалар өчен газета, журналлар | 4 |
| 7 | Для поэта природа - это мир живой  и таинственный./Шагыйрь өчен табигать серле һәм җанлы дөнья | 6 |
| 8 | Интересные и смешные истории/Кызык һәм көлке хәлләр | 6 |
| | Всего/Барлыгы | 68 |

Тематическое планирование. Тематик планлаштыру

3 класс/3 сыйныф

| т/с | Названия глав/ Бүлек исемнәре | Кол-во часов Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Наблюдаем и делимся впечатлениями Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз | 14 |
| 2 | Учимся секретам сравнения Чагыштырулар серенә төшенәбез | 6 |
| 3 | Учимся  понимать  чувства людей. Кешеләрнең хисләрен аңларга тырышабыз | 7 |
| 4 | О любви. Ярату турында | 9 |
| 5 | Набираемся жизненного опыта. Хикмәтле тормыш тәҗрибәсен туплыйбыз | 7 |
| 6 | Ищем секреты юмора. Көлке серләрен эзлибез | |
| 7 | Как рождается герой. Герой ничек туа | 9 |
| 8 | Сравниваем прошлое с настоящим. Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз | 11 |
| **Всего/ Барлыгы** | | 68 |

Тематическое планирование. Тематик планлаштыру
4 класс. 4 сыйныф

| №т/с № п/п | Название раздела. Бүлек исеме | Количество часов Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Изучаем каноны волшебных сказок: заново переживаем прошлое, связываем с сегодняшней жизнью. Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез. | 14 |
| 2 | Рассказываем на основе фольклора. Знакомимся через эпосы, мифы и легенды с историей, а авторские сказки зовут нас в мир чувств. Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легенда аша тарих белән танышабыз, ә авторәкиятләре хисләр дөньясына чакыра. | 6 |
| 3 | Через творчество поэтов и художников учимся понимать красоту природы и людей. Шагырьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез. | 8 |
| 4 | Знакомимся с жизнью сверстников, живших до нас. Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз. | 6 |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Стараемся понимать, как воздействует на нас прекрасное. Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз. | 10 |
| 6 | Сколько дорог проходит человек, чтобы стать на Земле Человеком? Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә. | 10 |
| 7 | Выясняем особенности мира искусства. Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз. | 4 |
| 8 | Если у народа нет прошлого, то и будущего нет. Думаем о Родине. Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган ил турында уйланабыз. | 10 |
| **Всего Барлыгы** | | 68 |

**Календарно-тематическое планирование курса**

**Календарь – тематик планлаштыру**

**1-класс**

| **№ т/с** | **Название раздела. Тема урока. Бүлек исеме. Дәрес темасы** | **Кол-во часов Сәгать саны** | **Дата проведения Үткәрү вакыты** | | **Примечание Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| Добукварный период. Әзерлек чоры – 3 сәгать | | | | | |
| 1 чирек | | | 9 | | |
| 1. | Сказка по картине.Речь. Сказки “Өч кыз”, “ Куян кызы».<br>Рәсем буенча әкият төзү. Сөйләм. Өч кыз, Куян кызы әкиятләре. | 1 | 3.09 | | |
| 2. | Текст. Предложене. Слово.<br>Текст.Текст кисәге буларак җөмлә. Җөмлә кисәге буларак сүз. | 1 | 10.09 | | |
| 3. | Слово-предмет, слово- движение, слово- признак предмета.<br>Предмет,хәрәкәт, билгене белдергән сүзләр. Ярдәмлек сүз. | 1 | 17.09 | | |
| Букварный период. Әлифба чоры – 20 сәгать | | | | | |
| 4. | Звуки [а], [ә].Буквы А,а, Ә,ә . [а], [ә] авазлары. А,а, Ә,ә хәрефләре. | 1 | 24.09 | | |
| 5. | Звуки[ы],[э.]Буквы Ы,ы,Э,э. [ы] ,[э] авазлары. Ы,ы, Э, э хәрефләре | 1 | 1.10 | | |
| 6. | Звуки[и],[у].Буквы И, и, У, у. [и],[у] авазлары. И,и, У, у хәрефләре. | 1 | 8.10 | | |
| 7. | Звуки[ү],[о].Буквы Ү,ү.О,о. [ү], [о] авазлары. Ү,ү, О, о хәрефләре. | 1 | 15.10 | | |
| 8. | Звук[ө].Буквы Ө,ө.Буквы о-ы,ө-е. [ө] авазы. Ө,ө хәрефләре. О-ы, ө-э хәрефләре. | 1 | 22.10 | | |
| 9. | Звуки[л],[н].БуквыЛ,л,Н,н. [л], [н] авазлары. Л,л, Н, н хәрефләре. | 1 | 29.10 | | |
| 2 четверть-7 часов.2 чирек – 7 сәгать | | | | | |
| 10. | Звуки[м][р].Буквы М,м,Р,р. [м], [р]авазлары. М, м, Р, р хәрефләре. | 1 | 12.11 | | |
| 11. | Звуки[й],[ң].Буквы Й,й,ң. [й], [ң]авазлары. Й,й, ң хәрефләре | 1 | 19.11 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Буквы Я,я. Обозначение звуков [йа], [йә] буквой я. Я, я хәрефләре. Аларның ике аваз белдерүләре. | 1 | 26.11 | | |
| 13. | Буквы Ю,ю, Е,е. Обозначение звуков [йу], [йү] [йэ], [йы] буквами ю, е.. Ю,ю, Е,е хәрефләре, аланың ике аваз белдерүләре. | 1 | 3.12 | | |
| 14. | Звуки[т],[д]..Буквы Т,т,Д,д.[т], [д] авазлары. Т, т, Д, д хәрефләре. | 1 | 10.12 | | |
| 15. | Звуки[с],[з].Буквы С,с,З,з.[с], [з] авазлары. З,з, С,с хәрефләре. | 1 | 17.12 | | |
| 16. | Звуки[к],[г].Буквы К,к,Г,г.[к], [г] авазлары. Г, г, К,к хәрефләре. | 1 | 24.12 | | |
| 3 четверть-9 часов. 3 чирек – 9 сәгать | | | | | |
| 17. | Звуки[w],[в],[ф].Буквы В,в,Ф,ф. [w], [в], [ф] авазы. В, в, Ф, ф хәрефләре. | 1 | 14.01 | | |
| 18. | Звуки[б],[п].Буквы Б,б,П,п. [б], [п] авазлары. Б,б, П, п хәрефләре. | 1 | 21.01 | | |
| 19. | Звуки[ж],[ш].Буквы Ж,ж,Ш,ш. [ж], [ш] авазы. Ж, ж, Ш,ш хәрефләре. | | 28.01 | | |
| 20. | Звуки[җ],[ч].Буквы Җ,җ,Ч,ч. [җ], [ч] авазы. Җ, җ, Ч, ч хәрефләре. | 1 | 4.02 | | |
| 21. | Звуки [х],[һ].Буквы Х,х,Һ,һ. [х], [һ] авазлары. Х, х, Һ, һ хәрефләре. | 1 | 18.02 | | |
| 22. | Звуки[йо],[щ].Буквы Ё,ё,Щ,щ. [йо], [щ] авазлары.Ё,ё, Щ, щ хәрефләре. | 1 | 25.02 | | |
| 23. | Звуки [къ],[гъ][ц].Буквы ъ,ь,Ц,ц. [ц], [къ], [гъ] авазлары. Ь, ъ, Ц, ц хәрефләре. | 1 | 4.03 | | |
| Послебукварный период-10 часов .Әлифбадан соңгы чор – 10 сәгать | | | | | |
| 24. | Мой родной язык-татарский. Туган телем - татар теле. | 1 | 11.03 | | |
| 25. | Зима наступила. Кыш килде. | 1 | 18.03 | | |
| 4 четверть – 8часов. 4 чирек – 8 сәгать | | | | | |
| 26. | Семья.Гаилә. | 1 | 1.04 | | |
| 27. | Этика-эстетика. Әдәп - әхлак. | 1 | 8.04 | | |
| 28. | Где труд, там и счастье. Иң мөкатдәс нәрсә - эш. | 1 | 15.04 | | |
| 29. | Растительный и животный мир.Үсемлекләр һәм җәнлекләр дөньясы. | 1 | 22.04 | | |
| 30. | Весна идет. Яз килә, яз көлә. | 1 | 29.04 | | |
| 31. | Лето. Ямьле җәй җитә. | 1 | 6.05 | | |
| 32. | Татарское устное народное творчество.Татар халык авыз иҗаты. | 1 | 13.05 | | |
| 33. | Известные татарские писатели. Күренекле татар язучылары. | 1 | 20.05 | | |

**Календарно-тематическое планирование по литературному чтению на родном (татарском) языке/**

**Уку курсын календарь – тематик планлаштыру**

**2 класс/2 сыйныф**

| № т/с | Название главы /Бүлек исеме<br>Тема урока/Дәрес темасы | Кол-во часов/ | Сроки/<br>Үткәрү вакыты | | Примечание/<br>Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |

| | | Сәгать саны | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 четверть/чирек – 16 часов/16сәгать | | | | | |
| В гостях у знающего ежа/ Белдекле керпедә кунакта – 11 сәгать | | | | | |
| 1,2 | В гостях у знающего Ежа. Особенности жанра произведения Г. Тукая “Сказка о козе и баране”/Белдекле Керпедә кунакта. Г. Тукайның "Кәҗә белән Сарык әкиятенең" жанр үзенчәлеге. | 2 | 04.09 | | |
| 3,4 | Народные сказки о животных/Хайваннар турында халык әкиятләре. | 2 | 11.09 | | |
| 5,6 | Народные сказки о домашних животных /Йорт хайваннары турында халык әкиятләре. | 2 | 18.09 | | |
| 7,8 | Сказки о диких животных/ Кыргый җәнлекләр турында әкиятләр | 2 | 25.09 | | |
| 9,10 | Пусть будет хоть емного своего ума/Аз булса да, үз акылың булсын. | 2 | 02.10 | | |
| 11,12 | Гуцулские народные сказки о животных/Җәнлекләр турында гуцул халык әкияте | 2 | 09.10 | | |
| 13,14 | Волшебные сказки татарского народа/Татар халкының тылсымлы әкиятләре. | 2 | 16.10 | | |
| 15,16 | Общая идея между автоскими и древними сказками/Автор әкиятләре белән борынгы әкиятләр арасындагы идея уртаклыгы. | 2 | 23.10 | | |
| 17,18 | Шуточные задачи в произведениях Ш.Галиева/Ш.Галиев әсәрләрендә мәзәк мәсьәләләр. | 2 | 13.10 | | |
| 2 четверть/чирек – 15 часов/15сәгать | | | | | |
| 19,20 | Вымышленные сказки/Уйдырма әкиятләр. | 2 | 20.11 | | |
| 21,22 | Поэтические произведения о насекомых. Автоские сказки./Бөҗәкләр турында шигъри әсәрләр. Автор әкиятләре. | 2 | 27.11 | | |
| В гостях у Незнайки /Белмәмештә кунакта – 2 часа/сәгать | | | | | |
| 23,24 | В гостях у Незнайки. Современный ребенок./Белмәмештә кунакта. Замана баласы. | 2 | 04.12 | | |
| 25,26 | Труд учит труду. Настоящий человек должен люить свою Родину./Эш эшкә өйрәтә. Илен сөйгән -ир булган. | 2 | 11.12 | | |
| У образованной Совы/ Укымышлы Ябалак янында – 2 часа/сәгать | | | | | |
| 27,28 | Путешествие в “Дом музея”. Японские стихи./"Музей йортына" сәяхәт. Япон шигыре. | 2 | 18.12 | | |
| 29,30 | Короткие стихи. Единство сказки и правды./Кыска шигырьләр. Әкият һәм чынбарлык берлеге. | 2 | 25.12 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| В берлоге у Медведя/Аю өнендә – 1 час/сәгать | | | | | |
| 31,32 | В берлоге у Медведя. Наблюдательный человек – счастливый человек. Письмо в клуб школы “Секретный ключ”./ Аю өнендә. Күзәтә белгән кеше-бәхетле кеше. "Серле ачкыч" мәктәп клубына хат язу. | 2 | 15.01 | | |
| 3 четверть/чирек – 22 часов/22 сәгать | | | | | |
| Точка зрения/Күрү ноктасы – 11 часов/сәгать | | | | | |
| 33,34 | Обучение приемам “Точка зрения”. Путешествие в “Дом музея”. / Күзәтү ноктасы алымнары белән таныштыру. "Музей йортына" сәяхәт. | 2 | 22.01 | | |
| 35,36 | Новые способы изучения мира. Мир, рожденный мечтами./Дөньяны танып белүнең яңа ысуллары. Хыялда тудырылган дөнья. | 2 | 29.01 | | |
| 37,38 | Путешествие в “Дом музея”. Глаз души./"Музей йортына" сәяхәт. Күңел күзе | 2 | 05.02 | | |
| 39,40 | На что похожа луна? Разносторонний взгляд на мир./Ай нәрсәгә охшаган? Дөньяга төрлечә караш. | 2 | 12.02 | | |
| 41,42 | Знакомство с миром./Дөнья белән танышу. | 2 | 19.02 | | |
| 43,44 | Весь мир в капельке воды. Наблюдение в бинокль./Бер тамчы суга дөнья сыйган. Бинокольдән күзәтү. | 2 | 26.02 | | |
| 45,46 | Я смотрю на тебя, а ты на меня./Син-миңа, мин сиңа карыйм. | 2 | 04.03 | | |
| 47,48 | Мы смотрим на них, они на нас. И растения мечтают./ Алар-безгә, без аларга карыйбыз. Үсемлекләр дә хыяллана. | 2 | 11.03 | | |
| 49,50 | Путешествие в “Дом музея”. Разные взгляды на один предмет./"Музей йортына" сәяхәт. Бер үк предметка төрле караш. | 2 | 18.03 | | |
| 51,52 | Маленький да удаленький. Путешествие в “Дом музея”. Заседание клуба школы “Секретный ключ”./Кечкенә - төш кенә. "Музей йортына" сәяхәт. "Серле ачкыч" мәктәп клубы утырышы. | 2 | 25.03 | | |
| 4 четверть/чирек – 15 часов/15сәгать | | | | | |
| 53,54 | Я всегда останусь самим собой. Кого что радует./Мин һәрвакыт үзем булып калам. Кем нәрсәгә шатлана. | 2 | 01.04 | | |
| Газеты и журналы для детей /Балалар өчен газета һәм журналлар – 2 часа/сәгать | | | | | |
| 55,56 | Как распространяются новости. Детские журналы./Яңалыклар ничек тарала. Балалар журналлары. | 2 | 08.04 | | |
| 57,58 | Детские газеты. Заседание клуба школы “Секретный ключ”./Балалар газеталары. "Серле ачкыч" мәктәп клубы утырышы. | 2 | 15.04 | | |
| Для поэта природа - это мир живой и таинственный./Шагыйрь өчен табигать - серле һәм җанлы дөнья – 2 часа/сәгать | | | | | |
| 59,60 | Для поэта природа - это мир живой и таинственный. У светлого окошка./Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья. Якты тәрәзә каршында. | 2 | 22.04 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 61,62 | Красота зимнего леса. Грусть светлого озера./Кышкы урман матурлыгы. Якты күл сагышы. | 2 | 29.04 | | |
| Интересные и смешные истории /Кызык һәм көлке хәлләр - 3 часа/сәгать | | | | | |
| 63,64 | Как рождается смех. Шутка тоже имеет смысл./Көлке ничек туа . Шаяртуның да бер төп мәгънәсе була. | 2 | 06.05 | | |
| 65,66 | Самый удивительный и самый смешной. Удивительные представления./Гаҗәпнең дә гаҗәбе, мәзәкнең дә мәзәге. Искитмәле тамашалар | 2 | 13.05 | | |
| 67,68 | Письмо в клуб школы “Секретный ключ”. Итоги учебного года. Задания на лето./"Серле ачкыч" мәктәп клубына хат язу. Уку елын йомгаклау. Җәйге биремнәр | 2 | 20.05 | | |

**Календарно-тематическое планирование по литературному чтению на родном (татарском) языке/**

**Уку курсын календарь – тематик планлаштыру**

**3 класс/3 сыйныф**

| **№** | **Название раздела (блока) Бүлек исеме** <br> **Тема урока Дәрес темасы** | **Количество часов** | **Дата проведения** | | **Примечание** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1 четверть – 18 часов 1 чирек – 18 сәгать | | | | | |
| Наблюдаем и делимся впечатлениями - 7 часов. Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз – 7 сәгать | | | | | |
| 1,2 | Самое весёлое время – лето.Иң күңелле чак. Җәйне сагыну | 2 | 4.09 | | |
| 3,4 | На рисунках- облака. Выходной день дождя. Күк йөзендә болыт - рәсемнәр. Яңгырның ял көне | 2 | 11.09 | | |
| 5,6 | Листопад. Золотая осень. Җир өстенә яфрак ява. Алтын көз | 2 | 18.09 | | |
| 7,8 | Дикие гуси летят на юг. Домашние гуси – удивительные птицы.Кыр казлары китә җылы якка. Йорт казлары — гаҗәп кызык кошлар | 2 | 25.09 | | |
| 9,10 | Попугай- воспитатель. Записная книжка Аниса Шакирова.Тәрбияче попугай. Әнис Шакировның куен дәфтәре | 2 | 2.10 | | |
| 11,12 | Заседание школьног о клуба. "Серле ачкыч" мәктәп клубы утырышы | 2 | 9.10 | | |
| 13,14 | Таинственный, певучий родник. Подвиг Сарбая. Серле чишмә, моңлы чишмә. Сарбайның батырлыгы | 2 | 16.10 | | |
| Учися секретам сравнения – 3 часа Чагыштырулар серенә төшенәбез – 3 сәгать | | | | | |
| 15,16 | Труд кормит, лень портит. У каждого зверя свой цвет. Эш кешене тәрбияли, ялкаулык боза. Һәр җәнлекнең үз төсе | 2 | 23.10 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17,18 | Ну заяц, заяц. Задним умом дело не поправишь.Эш үткәч, үкенүдән файда юк. И куян, куян... | 2 | 13.11 | | |
| 2 четверть 14 часов 2 чирек – 14 сәгать | | | | | |
| 19,20 | Среди животных тоже есть царь. Беда жадности. Җәнлекләр арасында да патша була. Комсызлык китергән бәла | 2 | 20.11 | | |
| Учимся понимать чувства людей- 4 часа Кешеләрнең хисләрен аңларга тырышабыз – 4 сәгать | | | | | |
| 21,22 | В мире мечты. Котёнок Шукбай.Хыял дөньясында. Мәче малае Шукбай | 2 | 27.11 | | |
| 23,24 | Кошки живут тоже как люди. Заседание школьного клуба. Мәчеләр дә кешеләрчә яши. «Серле ачкыч» мәктәп клубы утырышы | 2 | 4.12 | | |
| 25,26 | Мечта детей. Четвероногий друг.Нәниләрнең хыялы. Дүрт аяклы дустым | 2 | 11.12 | | |
| 27,28 | Есть место подвигу на земле. Батырлыкка җирдә урын бар. | 2 | 18.12 | | |
| О любви - 4 часа. Ярату турында – 4 сәгать | | | | | |
| 29,30 | Люблю всех. Приключения деревни. Под летним солнцем. Барысын да яратам. Авыл хикмәтләре. Җәйге кояш астында | 2 | 25.12 | | |
| 31,32 | Радость - это здоровье. Царь луга. Шатлык - тәнгә сихәт. Болын патшасы | 2 | 15.01 | | |
| 3 четверть -20 часов 3 чирек – 20 сәгать | | | | | |
| 33,34 | Около родника. Зима родного края.Чишмә буенда. Туган як кышы | 2 | 22.01 | | |
| 35,36 | Снег –это признак богатства. Радость зимы. Кар — ул муллык билгесе. Кыш шатлыгы | 2 | 29.01 | | |
| Набираемся жизненного опыта – 3 часа. Хикмәтле тормыш тәҗрибәсен туплыйбыз – 3 сәгать | | | | | |
| 37,38 | Тайна басни. Мудрость спасёт от смерти. Мәсәл серләренә төшенәбез. Тапкырлык үлемнән коткара. | 2 | 5.02 | | |
| 39,40 | Где сила не может, там ум поможет. Көч җитмәслек нәрсәне акыл белән җиңеп була | 2 | 12.02 | | |
| 41,42 | Каждой цели есть средство.Каков мастер, таково и дело. Сила в дружбе. Һәр максатка чара бар. Эшең барып чыкмаса, гаепне үзеңнән эзлә. Бердәмлектә көч | 2 | 19.02 | | |
| Ищем секреты юмора – 2 часа. Көлке серләрен эзлибез – 2 сәгать | | | | | |
| 43,44 | Не стыдно не знать, стыдно не учиться. Кто любит трудиться, того и лень сторонится. Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү - гаеп. Белгән белгәнен эшләр | 2 | 18.02 | | |
| 45,46 | Кто грамоте горазд, тому не пропасть. Бүләк зур булмас, укыган кеше хур булмас | 2 | 26.02 | | |
| Как рождается герой – 5 часов Герой ничек туа – 5 сәгать | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 47,48 | Маленькое дело лучше большого безделья. Каков ум, таков и разум. Акылның кадере — әдәп белән, куәтнең кадере - сәләт белән. Көнең бушка үтмәсен | 2 | 4.03 | | |
| 49,50 | Рукой победишь одного, а головой – тысячи. Изучение Ф.Яруллина “Тылсымлы ачкыч” Беләге юан — берне егар, белеме булган — меңне егар. Ф. Яруллин. «Тылсымлы ачкыч». | 2 | 11.03 | | |
| 51,52 | Чтобы много знать –надо много читать. Книга –источник знаний. Белер өчен дөресен, бик күп укырга кирәк. Гыйлем ачкычы — китап | 2 | 18.03 | | |
| 4 четверть – 16часов. 4 чирек – 16 сәгать | | | | | |
| 53,54 | Текут капли. Первая гром. Шыбырдашып тама тамчылар. Беренче күкрәү | 2 | 1.04 | | |
| 55,56 | Природа – загадочная книга. Долгожданные дожди. Пернатые друзья. Табигать — иң серле китап. Шифалы яңгырлар. Канатлы дуслар | 2 | 8.04 | | |
| Сравниваем прошлое с настоящим – 6 часов Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз – 6 сәгать | | | | | |
| 57,58 | Не забудь прошлое,ты. Старинная крепость. Үткәнеңне онытма син! Бик борынгы манара | 2 | 15.04 | | |
| 59,60 | Эхо войны. Семейное древо.Сугыш кайтавазы. Нәсел агачы | 2 | 22.04 | | |
| 61,62 | Они боролись за Родину. Спасибо вам, ветераны.Алар Ватан өчен көрәште. Рәхмәт сезгә, ветераннар! | 2 | 29.04 | | |
| 63,64 | Дети войны. Куда ведут крылья.Сугыш чоры балалары. Канатлар кая илтә? | 2 | 6.05 | | |
| 65,66 | Контрольный урок. Тест. Контроль дәрес. Тест | 2 | 13.05 | | |
| 67,68 | Я люблю тебя Татарстан! Казань – столица спорта. Мин яратам сине, Татарстан! Казан — спорт каласы. | 2 | 20.05 | | |

**Календарно-тематическое планирование курса/Курсның календарь – тематик планлаштыруы**
**4 класс/ 4 сыйныф.**

| № т/с № п/т | Название раздела. Бүлек исеме. Тема урока. Дәрес темасы. | Количество часов. Сәгать саны. | Время проведения. Үткәрү вакыты | | Примечание Искәрмә. |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План План | Факт Факт | |
| **1ая четверть.- 16 часов. 1 нче чирек - 16** сәгать | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Первая часть. 1.Изучаем каноны волшебных сказок: заново переживаем прошлое, связываем с сегодняшней жизнью- 7 часов.<br>Беренче кисәк. 1. Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез. – 7 сәгать** | | | | | |
| 1,2 | Первые люди, жившие на Земле. Как образовалась Земля? Җир йөзендә яшәгән беренче кешеләр. Җир ничек барлыкка килгән? | 2 | | | |
| 3,4 | О чём говорят древние легенды? Тотемные деревья. Борынгы легендалар ни сөйли? Тотем агачлары. | 2 | | | |
| 5,6 | Красавица родного края- белая берёза. Цветок папаротника. Туган як сылуы- ак каен. Абага ачәчәге. | 2 | | | |
| 7,8 | Цветок папаротника. Тотемные животные. Абага чәчәге. Тотем хайваннар. | 2 | | | |
| 9,10 | В татарской мифологии Белый волк. Герб Татарстана. Татар мифологиясендә Ак бүре. Татарстан гербы. | 2 | | | |
| 11,12 | Белый волк (Татарская народная сказка). Ак бүре (Татар халык әкияте). | 2 | | | |
| 13,14 | В сказках Белая Змея. Царь змей Шахмара. Әкиятләрдә Ак елан. Еланнар патшасы Шаһмара. | 2 | | | |
| **2. Рассказываем на основе фольклора. Знакомимся через эпосы, мифы и легенды с историей, а авторские сказки зовут нас в мир чувств- 3 часа.<br>2. Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легенда аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра – 3 сәгать** | | | | | |
| 15,16 | Древний поэт- Кол Гали. Борынгы шагыйрь - Кол Гали. | 2 | | | |
| 17,18 | Легенда о Йосыфе. Мы дети- татары. Кыйссаи Йосыф. Без татар балалары. | 2 | | | |
| **2ая четверть- 15 часов.<br>2 нче чирек – 15 сәгать.** | | | | | |
| 19,20 | В подводном царстве. Су асты патшалыгында. | 2 | | | |
| **3. Через творчество поэтов и художников учимся понимать красоту природы и людей- 4 часа.<br>3. Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез – 4 сәгать.** | | | | | |
| 21,22 | Что мне нужно на Земле? Стихи Шаехзады Бабича. Җирдә миңа ни кирәк? Шәехзадә Бабич шигырьләре. | 2 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 23,24 | Мгновения осенней природы. Көзге табигать мизгелләре. | 2 | | | |
| 25,26 | Красота утра- радость для души. Иртә яме, иртә моңы - җан азыгы. | 2 | | | |
| 27,28 | Нельзя говорить неправду, какой бы красивой она ни была. Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә. | 2 | | | |
| **4. Знакомимся с жизнью сверстников, живших до нас- 3 часа.**<br>**4. Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз - 3 сәгать.** | | | | | |
| 30,31 | Мучительная судьба. Газаплы язмыш. | 2 | | | |
| 32,34 | Детство, полное слёз. Күз яшьле балачак. | 2 | | | |
| **3ья четверть- 22 часов.**<br>**3 нче чирек – 22 сәгать.** | | | | | |
| 35,36 | Воспоминания детства. Балачак хәтирәләре. | 2 | | | |
| | **Вторая часть. 5. Стараемся понимать, как воздействует на нас прекрасное.**<br>**Икенче кисәк. 5. Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз.** | | 2 | | |
| 37,38 | Пусть дни мои будут бурными. Көннәрем гөрләп торсын. | 2 | | | |
| 39,40 | Вся земля белым-бела. Бөтен дөнья ак кына. | 2 | | | |
| 41,42 | Мир прекрасного. Матурлык дөньясы. | 2 | | | |
| 43,44 | Отражение в Волге родного края. Туган як - Идел көзгесендә. | 2 | | | |
| 45,46 | Природа- волшебный мир. Табигать - серле дөнья. | 2 | | | |
| **6. Сколько дорог проходит человек, чтобы стать на Земле Человеком?- 5 часов.**<br>**6. Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә? - 5 сәгать.** | | | | | |
| 47,48 | Волшебная,могущественная трава. Тылсымлы, кодрәтле үлән. | 2 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 49,50 | Приключения Непослушайки. Кирлемән маҗаралары. | 2 | | | |
| 51,52 | Надо знать секреты грибов. Гөмбәләр серен белү кирәк. | 2 | | | |
| 53,54 | Сундук бабушки Бану. Бану әби сабагы. | 2 | | | |
| **4ая четверть- 15 часов./4 нче чирек – 15 сәгать.** | | | | | |
| 55,56 | Секреты приготовления вкусного супа. Аш пешерү хикмәтләре. | 2 | | | |
| **7. Выясняем особенности мира искусства- 2 часа.**<br>**7. Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз – 2 сәгать.** | | | | | |
| 57,58 | Трудности ухода за гусятами. Бәбкә үстерү кыенлыклары. | 2 | | | |
| 59,60 | Проделки весны. Яз галәмәтләре. | 2 | | | |
| **8. Если у народа нет прошлого, то и будущего нет. Думаем о Родине - 5 часов.**<br>**8. Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган ил турында уйланабыз – 5 сәгать.** | | | | | |
| 61,62 | Каждому дорога его Родина. Һәркемгә үз Ватаны кадерле. | 2 | | | |
| 63,64 | Флаг Татарстана. Татарстан флагы. | 2 | | | |
| 65,66 | Мой смелый народ с большой историей. Зур тарихлы батыр халкым. | 2 | | | |
| 67,68 | Любовь- самое великое исцеление. Сөю - иң куәтле дәва. | 2 | | | |
| 69,70 | Повторение. Обобщающий урок. Кабатлау. Йомгаклау дәресе. | 2 | | | |